| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 апрель 2021 ел. № 23

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясе беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл жирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл жирлеге Советының 2021 елның 12 мартындагы 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл жирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» :

- 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле 3.18 пункт өстәргә:

«3.18. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булганда рөхсәт бирелми".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Смәел авыл җирлеге башлыгы: Р. Г. Йосыпов